# Болгар Туган Тел



17 июнь - 23 июнь
2017 ел

II смена

**Килдек әле Болгарга**
**Дуслар белән бергәләп,**
**Биеп, җырлап, шатланып,**
**Биш йөз кеше җыелып**
**Шулай бергә бергәләп**
**Яшибез дус-күмәкләп.**
**Шатланабыз һәр көнгә**
**Без бит Болгар җирендә!**

**Ашкын, хыяллан, бар алга**
**Син дә кушыл Болгарга.**
**Ачыла монда сәләт**
**Яхшыра безнең гадәт.**
**Милләтең өчен тырыш,**
**Әйдаманнарга булыш.**
**Бик рәхәт булыр монда**
**"Туган тел" аланында.**



# Яңадан Болгарга кайттык

«Болгар -Туган тел», минемчә, ул бер зур гаилә. Нибары 7 көн генә дәвам итсә дә, һәр сәлкешнең йөрәгендә нинди булса да эз калдыра. Сәләттә мин 2016-нчы елдан, миңа монда бик рәхәт, монда шундый җылы атмосфера.



17-23-нче июнь көннәрендә балалар шушы Изге җирдә рәхәтләнеп җәйге каникулларын уздыралар. Алар сменага Татарстаннан гына түгел, ә бик ерак шәһәрләрдән, районнардан киләләр.

Безнең өчен бик кызыклы программа төзелгән, көн дәвамында вакытыбыз булмый, тик тормыйбыз. Безнең өчен татар теле дәресләре, мастер-класслар, уеннар, кичке чаралар, дискәтүкләр уткәрелә.



Беренче көнне үк теркәлү узып, яшәү урыннарын таптык, аланнарга бүлендек, әйдаманнар белән таныштык, ә икенче көнне барысы да башланып китте. "Болгар -Туган тел"нең биюен өйрәндек, сүз уңаеннан, матур бию килеп чыга.(Көлә)

Изге Болгар җиренә көн саен хөрмәтле, мөхтәрәм кунаклар киләләр. Алар белән бергә "Болгар -Туган тел" форумының 2-нче сменасын рәсми ачып җибәрдек. Кунакларга бик күп итеп рәхмәәәт әйтәсе килә, безнең өчен бик күп тырышалар!

Көн саен төрле кызыклы чаралар уза. Мәсәлән, квест. Мавыктыргыч уен булып чыкты ул. Әлеге уен безнең төркемнәрне тагын да ныграк бәйләде, якынайтты. Кичке чарада бик текә интеллектуаль уен-



"Quiz time" узды. Безнең командабыз урын алмаса да, моңа бердә борчылмадык, чөнки җиңү мөһим түгел, ә катнашу мөһим.



Гомумән, сменада вакытны бик шәп уткәрәбез! Рәхмәт әйдаманнарга, рәхмәт форумның оештыручыларына!

*Сөмбел Латипова*

# Кызыклы очрашулар

18-нче июнь көнне безнең белән очрашуга төрле спикерлар килде. Алар арасында **Венера апа Иванова** да бар иде. Бөтенебез дә беләбез инде, ул бик шәп журналист, телевидениядә шәп алып баручы һәм, гомумән, кызык шәхес. Очрашу шәп үтте.

теләгән балалар үзләрен телевидениядә сынап карадылар. Барлык катнашучылар да биремне яхшы үтәделәр. Минемчә, бу булачак журналистларга, телевидениядә эшләүчеләргә шәп тәҗрибә, файдалы мастер-класс.

Очрашу мәгънәле, эчтәлекле булды, хәтта миңа журналистика белән моңарчы кызыксынмаган кешегә дә, журналистика өлкәсе ошап китте. Кем белә, бәлки, нәкъ менә бу очрашу миңа гомеремне журналистика белән бәйләп китәргә этәргеч булыр!





Венера апа безгә үзенең ничек журналистикага, туры эфирга, телевидениягә кереп киткәнен сөйләде, үзенең тәҗрибәсеннән чыгып киңәшләр бирде, сәхнәдә үзеңне тота белү, сөйләмеңне яхшырту, төрле күнегүләр турында сөйләде. Биргән сорауларга шундый тулы, киң җаваплар бирде. Очрашу азагында

Рәхмәәәт ,Венера апа!

*Сөмбел Латыйпова*



Бер көнне "Болгар-Туган тел" лагере кысаларында без беренче татар блогеры белән күрештек. Барлык яшь кешеләргә аның исеме инстаграм социаль челтәрендә билгеле – Татар Малай, ә чын исеме Ринат абый Галиәхмәтов.

Очрашуда ул безгә үзе һәм аның яраткан хоббие турында сөйләде. Төрле-төрле блогер яшәешенең лайфхаклар һәм аның алдында ачылган мөмкинлекләр турында әйтеп китте. Очрашу барышында мин үзем өчен менә нәрсә анладым: ул гади генә татар егете, әмма күпме энергия, күзләрендә кояш балкып тора аның.

Менә үз эшен яраткан кеше нинди булырга тиеш! Мин дә үскәч шулай үк эшемне яратырга телим! Бик кызык булды! Очрашудан китәсе бер дә китмәде, ә Ринат абый үз чиратында безнең белән фотога төште һәм инстаграмына элеп куйды. Мин аңа зур рәхмәт әйтәм!

Афәрин!

*Хәсән Әсхәдуллин*



# Әйдаман дөньясы

Сәлам, Дустым!
Кызу “Болгар-Туган Тел” аланы сиңа кайнар җәйге сәламнәр юллый!

Әйе, кызу, чөнки бүген “Болгар-Туган Тел” форумының икенче сменасының дүртенче көне бара – нәкъ кыл уртасы – иң күңелле һәм шәп вакыты. Балалар тирәлеккә, төркемгә һәм әйдаманнарга ияләшү этабын уңышлы үтеп яңа дуслар табу этабына күчте.



• Әйдаманлык – ул кызыклы дуслар дөньясы. Иң беренче юкка гына шушы җөмләне әйтмәдем, чөнки әйдаманнар кыш аеннан бирле үз мохитендәге кешеләр белән аралашып, кулдашлары, өлкән әйдаман апа-абыйлары белән дустанә мөнәсәбәтләр коралар. Һәм, минем уйлавымча, бу иң мөһим пунктларның берсе. Димәк, ни генә булмасын, әйдаманлык якынайта һәм туганлаштыра дисәк тә буладыр.

Ә әйдаманнар үзләре нинди этапта икән соң? Гомумән, әйдаман тормышы ул нинди? Булачак әйдаман үзендә кайсы сыйфатларны булдырырга тиеш? Мин – Энҗе апа – беренче тапкыр әйдаман ролендә. Шулай итеп, мин үткән өч көн нигезендә әлеге сорауларга җавапны табарга тырышып карадым.

### Димәк, киттек!

• Әйдаманлык – ул балаларга мәхәббәт. Әйе, һәр әйдаман балаларны яратырга һәм алар белән яхшы аралашырга тиеш. Бу – бәхәссез факт.

• Әйдаманлык – ул җаваплылык. Һәрбер әйдаман балаларның рухи һәм физик сәламәтлеге өчен җаваплы. Шуңа, бары тик тырыш һәм җаваплы кешеләр генә әйдаман була ала.

• Әйдаман – ул **супергерой**. Көненә өч сәгать кенә йоклап көне буе яхшы кәефтә йөрүче абый-апаларны супергеройлар дип атау ялгыш булмас. Шуңа күрә, булачак әйдаманнарга миннән киңәш: позитив рух, һәрвакыт шәп кәеф



*Әйдаманнар тормышыннан фактлар:*

• Сез йокларга яткач, апа-абыйларыгыз йокламый, аларның төнге җыелышлары башлана.
• Форум башланганчы әйдаманнар махсус курслар үтә.
•Әйдаманнар кулдашларын смена башланырга берничә көн калгач кына белә (әйе-әйе, алар балачактан бергә үсмәгәннәр).

*Энҗе Зиннурова*

**Бәлки без бу сменадан төрле әйберләр көтәбез-
дер, тик барыбызда да максат бер - яңа белемнәр алу,
яхшы дуслар, танышлар табу, яңа ачышлар ясау һәм
шәп кәеф булдыру!**

**Минем өчен уздыру урыны түгел, ә атмосфера һәм кешеләр мөһим...
Без барыбыз да чишмәдәй ташып торган энергия чыганаклары.**



**Сәләт - үз энергияң белән уртаклашыр һәм бүлешер өчен иң яхшы урын! Биредә һәрбер яңа көн ул - алтынчы көнгә бик яратылган җырдан иртәне башлау, көн кызыклы белемнәр һәм лаеклы режиссерлар, актерлар, мәдәният белгечләре һәм мавыктыргыч әйберләр белән уртаклашырга әзер булган кешеләр**



**белән аралашу. Ә кичен һәрчак бәйрәм, иҗади ачышлар, музыка һәм дуслар арасында искиткеч биюләр!
Шушы түгелме соң инде мавыктыргыч атмосфера?**

**Беренче көннән үк сезнең җылы кочагыгыз, көн дәвамында ачык елмаюларыгыз миңа бик ошады. Ә иң зур бүләк ул - сезнең үсүегезне күрү, талантыгыз белән сменаның темпын үзгәртү!
Безнең идеяләрнең чишмәсе ул - Сез! Һәрбер кунак һәм укытучы сезнең кызыксынуларыгызга нигезләнеп чакырылган. Һәм сез безнең идеяләрне уртаклашканга**

**безгә бииик күңелле! Бездә күкләр бик якын, тойдыгызмы? Без биредә бик бәхетле.
Бу смена тәмамланачак, тик мондагы кичерешләр, хисләр сезнең җаныгызны әле**



**озак вакытлар җылытып торачак...
Яңа җәй килеп, яңа дуслар, танышлар, ачышлар алып килгәнче, мондагы кебек күңеллелек беркая да булмаячак! Һәрбер мизгелнең тәмен белеп, матур мизгелләр белән аралаштырып яшәгез!
Безнең мәхәббәтебез сезгә тулысын белән күчсен иде!**


*Мәдинә апа Мөхтәсимова*



# Гүзәл төбәк

**Спас районының
Иң гүзәл җирендә
Урнашкан безнең
“Болгар-Туган тел”.
Төрле өлкәләрдән монда
Килә балалар
Талантлы, сәләтле,
Акыллы алар.
Яңа белем алалар,
Якын дуслар табалар
Һәм шәхси вакытларын
Бик күңелле уздыралар.**








**Баш мөхәррир:** Алинә апа Сысоева
Фотога төшерүче: Руслан абый Фәхретдинов
Газета чыгаруда катнаштылар: Сөмбел Латипова, Хәсән Әсхәдуллин, Энҗе Зиннурова, Мәдинә апа Мөхтәсимова.

Чыгарылган: 21.06.2017

bolgar_tugantel
selet_official